Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Ильбяковского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

ул. А.Валеева, д. 53, село Ильбяково,
Азнакаевский район, 423321

Татарстан Республикасы

Азнакай муниципаль районы
Илбәк авылы
җирлеге башкарма комитеты

А.Валеев урамы, 53нче йорт, Илбәк авылы,
Азнакай районы, 423321

Тел. (факс) 8(85592) 38-5-38; e-mail: Ilb.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» май 2018 ел №9

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 15 февралендәге 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге территориясендә планлаштыру документларын әзерләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 декабрендәге 455-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә карар бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 15 февралендәге 1 номерлы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2. 2.10 пунктта «Халык тыңлаулары» сүзләрен «Иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга.

1.3.2.11 пунктында «гавами тыңлаулар» сүзләрен «иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. 2.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.14. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегендә яшәүчеләргә җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар

нәтиҗәләре турында хәбәр итү көненнән алып иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар уздыру срогы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Уставы һәм (яисә) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм кимендә бер айдан һәм өч айдан артыграк була алмый.».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Л.Р.Әсәдуллина